**Добрый день!**
**Уважаемая СарияХарисовна!**
**Уважаемые члены экспертного совета и приглашенные!**

Рад всех приветствовать и предлагаю Вашему вниманию свой доклад на татарском языке на тему «Деятельность Конституционного суда Республики Татарстан в вопросах защиты прав человека и гражданина, а также взаимодействие с Уполномоченным по правам человека в Республике Татарстан» //«Татарстан Республикасы Конституция судының кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләсендә эшчәнлеге, шулай ук Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән бәйләнеш» темасына докладымны тәкъдим итәм.

Бер үк вакытта оештырылган һәм узган елда 15 еллык юбилейларын билгеләп үткән Татарстан Республикасы Конституция суды белән Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты республикада кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклау механизмының аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр.

Мәсәлән, «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында катнашырга хокуклы. Конституция суды тарафыннан үзенең беренче утырышыннан башлап тикшерелә торган мәсьәләләргә

карата позициясен белдерер өчен башка дәүләт органнары белән бергә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дә һәрвакыт тыңлауларга чакырыла. Мондый практика үзен аклады — ул тулысынча кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларына яраша: Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил билгеләп җибәргән кешенең турыдан-туры суд утырышында катнашуы һәм аның позициясе, һичшиксез, Конституция судына үзләренең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итәр өчен мөрәҗәгать иткән гражданнарның яклану дәрәҗәсен арттыра.

Татарстан Республикасы Конституциясенең преамбуласы кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләренең өстенлегенбелдерә, аның нигезендә иң югары кыйммәтитеп — кеше, аның хокуклары һәм ирекләре билгеләнә, дәүләт исә аларны танырга, үтәргә һәм якларга тиеш, шуның өчен Конституция суды эшчәнлегенең иң әһәмиятле максаты итеп нәкъ менә кешенең һәм гражданның төп хокукларын һәм ирекләрен яклау таныла.

Гомумән алганда, Татарстан Республикасы Конституция судында төрле вакытта күпчелекне гражданнарны социаль яклау, торак законнарын җайга салу хокукый нормаларын тикшерү тәшкил итте.НигездәТатарстан Республикасы Конституция судына социаль яктан иң якланмаган гражданнар категориясе мөрәҗәгать итә: пенсионерлар, сугыш һәм хезмәт ветераннары, инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр, күп балалы гаиләләр, элекке балигъ яшькә җитмәгән фашизм тоткыннары, сәяси репрессия корбаннары һәм халыкның башка якланмаган катлавы.

Татарстан Республикасы Конституция судының хокук яклау эшчәнлеге аерым физик затларга гына кагылып калмыйча, аларның берләшмәләрен, шул исәптән юридик затларны да эченә ала. Мәсәлән, 2004 елның 5 июлендәге карарында Татарстан Республикасы Конституция суды шундый хокукый позиция формалаштырды: берләшмәләрнең эшчәнлеге аларның әгъзалары (катнашучылары, оештыручылары) булган гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруга бәйле булган очракта, гражданнар һәм алар тарафыннан оештырылган берләшмәләр судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Кайбер очракларда кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү дәгъвалана торган норматив нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануны таләп итә, бу исә аларның юридик көчләрен югалтуларын китереп чыгара. Мәсәлән, 2015 елда Татарстан Республикасы Конституция судында Әлмәт шәһәренең гомуми кулланылыштагы муниципаль автомобиль юллары буенча хәрәкәт итеп транспорт чараларында авыр йөкләр күчерүче затларның конституциячел хокуклары якланды. Бу эшне караган вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Әлмәт шәһәрендә авыр йөкләр күчергәндә юлларга зарар салуны каплау максаты белән транспорт чарасы хуҗаларыннан берьюлы ике төрле түләү алынганын ачыклады. Боларның берсе — федераль закон билгеләгән түләү, икенчесе — муниципаль актлар белән билгеләнгән түләү. Шул ук вакытта Әлмәт муниципаль районы Советы тарафыннан билгеләнгән түләү канунсыз рәвештә алынган.

Дәгъвалана торган хокукый нигезләмәләрнең Төп законга каршы килүләрен танымыйча һәм, димәк, хокукый мәйданнан чыгармыйча, конституциячел-хокукый мәгънәләрен ачыклауТатарстан Конституция судының республикадагы хокукый системага иң еш кулланыла торган хокук яклауның тәэсир итү чарасы булды. Мондый практиканың кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау буенча Конституция суды эшләрен башкару максатын гамәлгә ашыру мәсьәләсендә җитди нәтиҗәләр бирүен билгеләп китү дә кирәк, чөнки суд тарафыннан ачыкланган хокукый нормаларның конституциячел-хокукый мәгънәсе һәркем өчен мәҗбүригә әверелә һәм хокук куллану практикасында аларның ничектер башкача аңлатылуларына юл калдырмый. Суд белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының үзара тыгыз бәйләнештә торулары сәбәпле Конституция судының дистәдән артык хокукый тәкъдимнәре гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүгә нигез булды.

Иң соңгы мисаллардан 2015 елның 1 декабрендәге 65-П номерлы карарны китерә алабыз. Конституция суды карарында бәян ителгән тәкъдим нәтиҗәсендә күрсәтелгән өлкәдә хокукый җайга салу камилләштерелде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 14 гыйнварындагы 9 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы үзенең сайтында берничә муниципаль район территориясендә, шәһәр округларында гавами чаралар үткәрү

турында гавами чараларны оештыручылар тарафыннан бирелгән хәбәрнамә хакында мәгълүматны урнаштыру йөкләнде.

Һичшиксез, гавами хакимият органнарының кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләсендә үзара бәйләнештә тору кирәклеге бәхәс тудырмый һәм ниндидер өстәмә дәлилләр таләп итми. Шуның белән бергә хезмәттәшлек итү нигезе булып, кагыйдә буларак, тиешле законнар яки башка норматив хокукый актлар тора. Татарстан Республикасы Конституция суды белән Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасындагы бәйләнеш нигезләре закон актларында да чагылыш таптылар.

Мәсәлән, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 81 һәм 85 статьяларында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленең Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының, шулай ук әле гамәлгә кермәгән халыкара һәм тышкы икътисади бәйләнешләр турындагы килешүләрнең конституциячеллеген тикшерү турында таләп белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы бар. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең мондый хокуктан инде файдалануын да билгеләп үтәргә кирәк. Мисал өчен, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил таләбенә бәйле рәвештә 2012 елның 21 февралендәге 47-П номерлы карар кабул ителде. Бу карар Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре эшчәнлеген оештыру турында нигезләмә белән Ашыгыч медицина

ярдәме бүлеге эшчәнлеген оештыру турында нигезләмәне тулысы белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясына (өченче өлеше) туры килми дип таныды, чөнки алар, кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына, аерым алганда яшәү һәм сәламәтлекне саклау конституциячел хокукларына кагылсалар да, халыкка белдерер өчен рәсми рәвештә матбугатта бастырып чыгарылмаганнар иде.

Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән бәйләнеше мәгълүмат өлкәсендә дә гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил Конституция судына Татарстан Республикасында кеше хокуклары үтәлүе турында ел саен докладлар юллап тора. Конституция суды, үз чиратында, Вәкаләтле вәкилгә каралган эшләр буенча кабул иткән карарларын җибәреп тора. Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча югары комиссар идарәсе тарафыннан оештырылып узган елны Казанда үткәрелгән III кеше хокуклары буенча халыкара җәйге мәктәп шулай ук фикер алышу өчен кызыклы мәйдан булды.

Ике арадагы хезмәттәшлек итү формаларын киңәйтү һәм, мисал өчен, гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендә уртак эш башлау максатка ярашлы гамәл булыр иде, дип уйлыйм. Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә бик актив катнаша һәм бу өлкәдә шактый гына уртак проектларны гамәлгә ашыра.

Шуңа күрә, Сезгә мөрәҗәгать итеп, Сәрия Харисовна, Татарстан Республикасы Конституция суды һәм Татарстан

Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасында хезмәттәшлек турында шушындый шартнамә төзүне тәкъдим итмәкче булам. Шартнамәдә, башка пунктлар белән бергә, безнең аппаратлар хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны бергәләп кабул итү графигын да раслап китәргә булыр иде. Суд һәм Вәкаләтле вәкил эшчәнлекләренең социаль юнәлештә булуларын исәпкә алып, түләүсез юридик консультацияләрне халыкны иң нык борчыган мәсьәләләр буенча алдан ук билгеләп куелган тематикаларда оештырып булыр иде. Мондый уртак эш Татарстан Республикасы Конституция суды белән Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасындагы үзара бәйләнешне яңа дәрәҗәгә күтәрер һәм алга таба республикада кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау буенча нәтиҗәле эшчәнлекләренә ярдәм итәр иде, дип уйлыйм.

**Игътибарыгыз өчен рәхмәт!**